РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Сухаревского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Сухрауавылжирлеге
Советы

423559, Нижнекамский район,
с. Сухарево, ул.Пролетарская, 12

423559, Түбән Кама районы,
Сухрау авылы, Пролетар урамы,12

тел./факс (8555) 44-11-44, электронный адрес: Suharevskoe.Sp@tatar.ru, сайт: www.suharevskoe-sp.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 26 ноябреннән № 25

Түбән Кама муниципаль районы
Сухрау авыл җирлеге Советының
«Җир салымы турында» 2018
елның 23 июлендә кабул ителгән
21 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Сухрау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Сухрау авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Сухрау авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2018 елның 23 июлендәге 21 номерлы карарына (2018 елның 19 декабрендәге 40 номерлы редакциясендә) (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарның 1.1. пунктындагы 1.1.1. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1.1. «1.1.1. физик затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелешеннән тыш, аларда торак төзелешен гамәлгә ашыру шартларында, физик һәм юридик затлар тарафыннан милеккә сатып алынган (бирелгән);»;

1.2. карарның 1.2. пунктындагы 1.2.2. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.2. торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары алып торган (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына карамый торган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокук өлешеннән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланыла

торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);»;

1.3. карарның 1.2. пунктындагы 1.2.3. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.3. шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән), эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган, шулай ук «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләрен;»

1.4. 4.2. пунктындагы 4.2.2. пунктчасын төшереп калдырырга.

1.5. карарның 3.2 пунктының гамәлдә булу вакытын 2020 елның 31 декабренә кадәр билгеләргә.

2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Сухрау авыл җирлеге
башлыгы Р.Р. Галимов